| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| **ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ** | **ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

***Постановление*** ***Карар***

***05 .03.2021*** ***г. Чистополь*** ***№ 31***

Чистай шәһәре Башкарма комитетының
«Чистай шәһәре Башкарма комитетының
Резерв фонды акчаларын тоту тәртибе
турындагы Нигезләмәне раслау хакында»
2013 елның 21 гыйнварындагы 5 номерлы
карарын үтәү үзенчәлекләре турында

Чистай шәһәр прокуратурасының 2021 елның 26 февралендәге 02-08-02-2021 номерлы протесты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләре нигезендә, Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Билгеләргә кирәк, 2022 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Башкарма комитетының Резерв фонды күләмен арттыру очракларына, Чистай шәһәре Башкарма комитетының «Чистай шәһәре Башкарма комитетының Резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 21 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган, Чистай шәһәре Башкарма комитеты резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәләр 2.2 пунктының нигезләмәләре кагылмый.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына, югарыда күрсәтелгән үзгәрешләр нигезендә, Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Н.А. Кармановага йөкләргә (килешү буенча).

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов